| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12.03.2021 с.Старое Дрожжаное №90

Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карарына таянып, «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибе турында» Башкарма комитет карары нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 03 сентябрендәге 380 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.6 пунктта:

а) дуртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) гражданнарны теркәү турында белешмәләр;»;

б) түбәндәге редакциядә сигез һәм тугыз абзацларын өстәргә:

«8) Салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләмәү турында белешмәләр.

9) инвалидлык төркемен күрсәтеп, инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмә (ташламалары булган гражданнар өчен).»

2) 3.4.1 пунктчасында:

а) дуртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) гражданнарны теркәү турында белешмәләр;»;

б) түбәндәге редакциядә сигез һәм тугыз абзацларын өстәргә:

«8) Салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләмәү турында белешмәләр.

9) инвалидлык төркемен күрсәтеп инвалидлык билгеләү фактын раслаучы белешмәләр (ташламалары булган гражданнар өчен).»;

3) 3.7.1 пунктчасында «исәпкә куюдан баш тарту турында» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле сүзләр өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче нәтиҗәне электрон рәвештә алу ысулын сайлаганда, мөрәҗәгать итүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә җибәрә.»;

4) 4.1 пунктчасында:

а) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Агымдагы контроль максатларында мәгълүматларның электрон базасында булган белешмәләр, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны үтәүче белгечләрнең телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка белешмәләр файдаланыла.

Белгечләр административ процедураларның срокларын бозу очраклары һәм сәбәпләре турында муниципаль хезмәт күрсәтүче орган житәкчесенә кичекмәстән хәбәр итәләр, шулай ук хокук бозуларны бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.С. Бикчуровка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе — Д.А.Сатдинов